ГЛАВА КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Гагарина, д.29, с. Куюк-Ерыкса,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ

Гагарин ур., 29 нче йорт, Көек-Ерыкса авылы,
Мамадыш районы, 422151

тел.(факс): (85563) 3-66-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru


Постановление — Карар

№ 1 — 29 гыйнвар 2016 ел

## 2016 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы чаралар планын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «2020 елга кадәр Россия Федерациясе дәүләтнең наркотикларга каршы сәясәте стратегиясен раслау турында» 2010 елның 09 июнендәге 690 номерлы Указына таянып, наркомания таралу куркынычын минимальләштерү максатларында һәм Мамадыш районы прокуратурасының 2015 елның 25 июнендәге 02-01-19-2015 номерлы тәкъдиме нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы комиссия төзергә. (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге Башкарма комитеты карамагында наркотикларга каршы комиссия турындагы нигезләмәне расларга . (2 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы чаралар планын расларга. (3 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:/ mamamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең «Норматив хокукый актлар» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге каранның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Көек Ерыкса авыл җирлеге
башлыгы Ф.Р.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге башлыгының 29 гыйнвар, 2016 ел, № 1 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек Ерыкса авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы наркотикларга каршы комиссия СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | Шәйхетдинов Фидәил Рафаэл улы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек Ерыкса авыл җирлеге башлыгы |
| Комиссия секретаре | Мальцева Светлана Григорий кызы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек Ерыкса авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре |
| Комиссия әгъзалары | Сәитов Айрат Сабит улы, полициянең участок уполномоченные |
| | Галиев Зәки Раиф улы МБОУ «Көек Ерыкса урта мәктәбе» МБОУ директоры |
| | Закирова Венера Сабир кызы, Көек Ерыкса ФАПы мөдире |
| | Баймурзина Лидия Иван кызы, МБОУ «Зур Шыя урта мәктәбе» МБОУ директоры |
| | Зарипова Резедә Хәсән кызы, Зур Шыя ФАПы мөдире |
| | Шигабеева Зимфира Мирзагаптулла кызы, «Гришкино төп белем бирү мәктәбе» МБОУ директоры |
| | Хабибрахманова Миннероза Садыйк кызы, Гришкино ФАПы мөдире |

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге башлыгының 29 гыйнвар, 2016 ел, № 1 карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге Башкарма комитеты карамагында наркотикларга каршы комиссия турындагы нигезләмә

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек Ерыкса авыл җирлеге комиссиясе (алга таба - Поселение) наркоманияне профилактикалау, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерү һәм бетерү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы орган булып тора. Комиссиянең кыскартылган исеме бар - АНК.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституцион законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарлары һәм боерыклары, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Дәүләт наркотикларга каршы комитеты карарлары, җирлекнең норматив-хокукый актлары һәм Мамадыш муниципаль районының АНК карарлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

3.Комиссия үз эшчәнлеген Мамадыш муниципаль районының наркотикларга каршы комиссиясе, Мамадыш районының хокук саклау органнары, мәгариф һәм сәламәтлек саклау учреждениеләре, авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлектә алып бара.

4. Комиссии җитәкчесе булып авыл җирлеге Башлыгы тора.

5. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

а) наркоманияне профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметү һәм бетерү буенча эшчәнлек;

б) торак пункт территориясендә наркоманиягә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

в) наркоманияне профилактикалау, аның барлыкка килүенә ярдәм итүче сәбәпләрне һәм шартларны бетерү, әлеге чараларны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту буенча чаралар эшләү;

г) торак пункт территориясендә наркоманияне профилактикалау буенча эшнең нәтиҗәлелеген анализлау, шулай ук аның нәтиҗәләрен киметү һәм бетерү, әлеге эшне камилләштерү буенча комиссия карарларын әзерләү;

д) наркоманиягә каршы тору буенча Россия Федерациясе законнарында каралган башка бурычларны хәл итү.

6.Үз бурычларын үтәү өчен комиссия түбәндәгеләргә хокулы:

а) үз компетенциясе чикләрендә наркоманияне профилактикалау, аның нәтиҗәләрен киметү һәм бетерү буенча поселок территориясендә эшчәнлекне оештыру, координацияләү һәм камилләштерүгә кагылышлы карарлар кабул итәргә, шулай ук аларның үтәлешен контрольдә тотарга;

б)комиссия эшендә катнашу өчен җирлекнең җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын һәм белгечләрен, шулай ук оешма һәм иҗтимагый берләшмә вәкилләрен ( аларның ризалыгы белән) җәлеп итәргә;

в) торак пункт территориясендәге иҗтимагый берләшмәләрдән, оешмалардан һәм вазифаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар һәм мәгълүмат сорарга һәм алырга.

7. Комиссия үз эшчәнлеген җирлек башлыгы раслаган планга ярашлы рәвештә алып бара.

8. Комиссия утырышлары кварталга бер тапкырдан да сирәгрәк үткәрелми. Кирәк булганда Комиссия рәисе карары буенча комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

9. Комиссия әгъзаларының аның утырышларында булуы мәҗбүри. Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен башка кешеләргә тапшырырга хокуклы түгел. Комиссия әгъзасы утырышта катнаша алмаган очракта, ул бу хакта комиссия рәисенә алдан хәбәр итәргә тиеш. Комиссия әгъзасы утырышта катнаша алмаган очракта, аның вазифаларын башкаручы кеше комиссия рәисе белән килешкәннән соң, киңәшмә тавышы хокукы белән утырышта катнаша ала.
10. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары утырышта карала торган мәсьәләләрне тикшергәндә тигез хокукларга ия. Комиссия утырышларында каралган мәсьәләләргә бәйле рәвештә, анда катнашуга башка кешеләр дә җәлеп ителергә мөмкин.
11. Комиссия карары Комиссия рәисе имзалаган протокол белән рәсмиләштерелә.
12. Комиссия эшчәнлеген оештыру һәм матди-техник тәэмин итүне җирлек башлыгы башкара. Бу максатлар өчен җирлек башлыгы үз компетенциясе чикләрендә әлеге эшчәнлекне оештыру функциональ бурычларына кергән вазифалы кешене ( АНК җаваплы секретаре) билгели.
13. АНК җаваплы секретаренең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
а) комиссиянең эш планы проектын эшләү;
б) Комиссия утырышларын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итү;
в) аның карарларының үтәлешен контрольдә тоту буенча Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү;
г) комиссия эшен оештыру һәм алып бару.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге башлыгының 29 гыйнвар, 2016 ел, № 1 карарына 3 нче кушымта

2016 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек Ерыкса авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы чаралар
ПЛАНЫ

| **№ п\п** | **Эчтәлек** | **башкаручы** | **үтәү вакыты** |
|---|---|---|---|
| 1. | Наркотикларга каршы комиссия утырышларын үткәрү | АНК | кварталга 1 тапкыр |
| 2. | Мәдәни-массакүләм һәм ял итү чаралары уздырыла торган урыннарда наркотик чаралар таралу фактлары турында мәгълүматны җыю, гомумиләштерү һәм анализлау. | АНК | даими |
| 3. | Китапханә, мәктәп базасында наркомания, алкоголизм, тәмәке тарту һәм ВИЧ-инфекция проблемалары буенча мәгълүмат банкын булдыру һәм аларга ярдәм итү | АНК | даими |
| 4. | Тар профильле белгечләрне (психолог, нарколог һ.б.) җәлеп итеп, авыр тормыш хәленә эләккән яшүсмерләргә консультацияләр үткәрү. | АНК, мәктәп | Кирәк булганда |
| 5. | Яшүсмерләргә тәмәке тарту, алкоголь, наркомания, ВИЧ кешенең сәламәтлегенә начар йогынты ясавы турында мәгълүматлаштыруның мониторингы. | Мәктәп, китапханә | даими |
| 6. | Авыл китапханәсендә наркоманияне профилактикалау буенча чаралар үткәрү (мәгълүмат стендлары, уку конференцияләре). | Китапханә | Сентябрь, декабрь |
| 7. | Наркомания һәм хокук бозуларны профилактикалау айлыгы үткәрү. | Авыл җирлегенең Башкарма комитеты, АНК, мәктәп. | Октябрь |
| 8. | "Наркотикларга-юк!" акциясен оештыру һәм үткәрү». | Клуб, мәктәп | Ноябрь |
| 9. | Наркотиклы үсемлекләрне юк итү буенча рейдлар үткәрү. | АНК, полиция | Октябрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Алкогольле продукция һәм сыра сату белән шөгыльләнүче сәүдә нокталары буенча рейдлар үткәрү. | АНК, полиция | Ай саен |
| 11. | Кичке вакытта дискотекаларны, яшьләр массакүләм чараларын тикшерү буенча рейдлар үткәрү. | АНК, полиция | Ай саен |
| 12. | 2017 елга АНК эш планын раслау | АНК | Декабрь 2016 ел |